«Раслыйм»
184 енче балалар бакчасы
мөдире

___________ Э. Ф.Литвинова

Литвинова Эндже Францизовна

Подписан: Литвинова Эндже Францизовна
DN: C=RU, S=Республика Татарстан (Татарстан), L=г. Казань, T=Заведующий, O="МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ""ДЕТСКИЙ САД №184 КОМБИНИРОВАННОГО ВИДА С ТАТАРСКИМ ЯЗЫКОМ ВОСПИТАНИЯ И ОБУЧЕНИЯ"" МОСКОВСКОГО РАЙОНА Г.КАЗАНИ", СНИЛС=04670721657, ИНН=165602389803, E=it-cbo@yandex.ru, G=Эндже Францизовна, SN=Литвинова, CN=Литвинова Эндже Францизовна
Основание: Я являюсь автором этого документа
Местоположение: место подписания
Дата: 2023.08.31 12:56:38+03'00'
Foxit Reader Версия: 10.1.3

# Казан шәһәре Мәскәү районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 184енче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем учреждениесенең

# 2023 – 2024 нче уку елына эш планы

**Кабул ителде:**
184-нче балалар бакчасы
Педагоглар киңәшмәсендә
Протокол № 4 “31” 05. 2023 ел

ЭЧТӘЛЕК

1. 2022-2023 уку елына анализ
2. 2023-2024 уку елына эш планы:
   - 2023-2024 нче уку елына балалар бакчасының методик темасы
   - Кадрлар белән эш
   - Аттестация
   - Инструктажлар
   - Гомуми хезмәт коллективы җыелышлары
   - Педагогик оештыру эшләре
   - 2023 – 2024 нче уку елына педагогик киңәшмәләр графигы
   - Консультацияләр
   - Семинар - практикумнар
   - Бәйгеләр, күргәзмәләр
   - Тематик көннәр. Күңел ачу кичәләре
   - Телләр турында законны тормышка ашыру буенча эш планы
   - Укыту – тәрбия процессында 2023 – 2024 нче уку елында педагогик тематик тикшерү
   - Тәрбия һәм белем бирү эшенә җитәкчелек итү һәм контроль
   - Оператив контроль
   - Тематик тикшерүләр
   - Фронталь тикшерү
   - Ата – аналар белән эш
   - 17 нче татар гимназиясенең 2023 – 2024 нче уку елына үзара эшчәнлек планы
   - Балаларны татар теленә өйрәтү буенча еллык эш планы
   - Административ – хуҗалык эшләре
   - Юл – транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча уздырыласы чаралар планы

Казан шәһәре Мәскәү районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 184 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем учреждениесе 1962 елдан бирле эшли. Проект егәрлеге (мощность) – 6 төркем, 120 урын, типлаштырылган торак, мәйданы – 1040 кв.м.

Бакча мөдире – Литвинова Энже Франгиз кызы.

2022 нче елның 01 сентябренә фактта булган балалар саны – **107** (107 – 2 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар), барлыгы 6 төркем:

2 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге 1 енче кечкенәләр төркеме – 1;
3 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге 2 енче кечкенәләр төркеме – 2;
4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге урта яшьтәге балалар төркеме – 1;
5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге зурлар (катнаш логопедия) төркеме – 1;
6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге (катнаш логопедия) мәктәпкә әзерлек төркеме – 1.

Балалар бакчасында төркемнәр 10,5 сәгать дәвамында (7.30 – 17.30) эшли.

Балалар бакчасында түбәндәге бүлмәләр җиһазландырылган:

- музыка һәм спорт залы,
- татар теле бүлмәсе,
- логопед бүлмәсе,
- методик бүлмә,
- медицина бүлмәсе

Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеге РФ һәм ТР ның Фән һәм Мәгариф Министрлыгы тарафыннан кабул ителгән төп, парциаль, коррекцион программаларга таянып башкарыла:

- Н.Е. Веракса, Т. С. Комарова, Э. М. Дорофеева редакциясендә "Туганнан мәктәпкә кадәр" мәктәпкәчә белем бирүнең инновацион программасын исәпкә алып, Казан шәһәре Мәскәү районының “Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 184 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” МББ ФДББС яраклы рәвештә эшләнгән төп белем бирү программасы, 2021 елның 1 сентябрендәге 1 нче педагогик берләшмәсендә кабул ителгән. 01.09.2021 елдан гамәлгә ашырыла;

- Т. Филичев, Г. Чиркинның сөйләме җитлекмәгән балаларны укыту һәм тәрбияләү программасы; - Г. Каше, Т. Филичевның фонетик төзелеше җитлекмәгән балаларны укыту программасы;

- Мәктәпкәчә белем бирүнең төбәк программасы “Сөенеч - танып белү шатлыгы” Р.К. Шәехова. - Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча уку-методик комплект:

- 1 комплект-татар телле балаларны рус теленә өйрәтү буенча "рус телен өйрәнәбез", С. М. Гаффарова җитәкчелегендәге иҗат төркеме.;

- 2 комплект-рус телле балаларны татар теленә өйрәтү буенча "Татарча сөйләшәбез" -" Татарча сөйләшәбез", З. М. Зарипова, Р. Г. Кидрячева җитәкчелегендәге иҗат төркеме.;
- 3 комплект-татар телле балаларны туган телгә өйрәтү буенча "Туган телде сөйлешәбез", Ф. В. Хәзрәтова җитәкчелегендәге иҗат төркеме.
- 4 комплект-мәктәпкә әзерлек төркемнәре балалары өчен "Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларный уйнатып" (татар телле балалар өчен) Авторы Шәехова Р. К., "бер - сүз, ике - сүз" (татар телен кызыклы өйрәтү) әсәрләре авторы Шәехова Р. К.

- «Гаиләдә, балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы», Закирова К. В., Кадырова Р. А.
- Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга экологик тәрбия бирү С. Н. Николаева;
- Мәктәпкәчә яшьтәге балалар иминлеге нигезләре, Р. Стёркина, О.Князева, Н. Авдеева.
- 2022-2023 нче уку елы дәверендә бакчада түләүсез түгәрәкләр оештырылды һәм эшләп килде:
  - «Яшь эколог» Гайнуллина А.Х.
  - «Мавыктыргыч әвәләү» Жамиева Г.Д.
  - «Сәламәт булыйк!» Бадертдинова А.Д.
  - «Умники и умнички» Хөснетдинова Д.Н.
  - «Әкияттә кунакта» Шәйхетдинова Г.Г.
  - “Әкият илендә” Рахманова З.Н.
  - “Балаларга - театр” Зиялиева Г.Р.


2022-2023 нче уку елы дәверендә бакчада түләүле түгәрәкләр оештырылды һәм эшләп килде:
• “Оригами дөньясы” (Мир оригами) – Бадертдинова А.Д.

• “Фантазерлар” (Фантазеры) - Жамиева Г.Д.
• “Күңелле ритмика” (Веселая ритмика) – Хөснеева Э.А.

Махсус белгечләрдән уку елы дәверендә музыка тәрбиячесе, укытучы-логопед, туган теле тәрбиячесе, өлкән тәрбияче һәм педагог-психолог эшләп килделәр.


**Педагогларның яшь күрсәткечләре:**

| уку елы | барлыгы | 20-25 | 25-30 | 30-40 | 40- |
|---|---|---|---|---|---|
| 2020- 2021 | 13 | 1 чел (7,69%) | - | 7 чел. (53, 85%) | 3 чел. (23,07%) |
| 2021- 2022 | 11 | - | 2 чел. (18%) | 4 чел. (37%) | 5 чел. (45%) |
| 2022- 2023 | 12 | - | 1 чел (8,3%) | 5 чел (41,7%) | 6 чел (50%) |




**Педагогларның белем дәрәҗәләре:**

| уку елы | | барлыгы | югары махсус белем | махсус урта белем | махсус белемсез |
|---|---|---|---|---|---|
| 2020-2021 | уку елының башы | 13 | 11 – 84,6% | 2 – 15% | - |
| | уку елының азагы | 12 | 11 – 91% | 1 – 8% | - |
| 2021-2022 | уку елының башы | 11 | 9 – 81% | 2 – 19% | - |
| | уку елының азагы | 11 | 9 – 81% | 2 – 19% | - |
| 2022-2023 | уку елының башы | 11 | 10 -90% | 1- 10% | - |
| | уку елының азагы | 12 | 11- 92% | 1 – 8% | - |




Педагогларның белем дәрәҗәләренә анализ ясау шуны күрсәтә: бакчада эшләүче педагоглар 90% югары махсус белемле.

**Педагогларның эш стажлары буенча күрсәткечләр**


| уку елы | педагог ларсаны | 1- 3 | 3- 5 | 5-10 | 10-15 | 15-20 | 20- 30 | 30 - |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2020-2021 | 13 | - | 2<br>15,5% | 3<br>23% | 3<br>23% | - | 5<br>38,5% | - |
| 2021-2022 | 11 | - | 1<br>(9%) | 3<br>(27%) | 3<br>27% | 1<br>(9%) | 3<br>(27%) | - |
| 2022-2023 | 12 | - | 2<br>(16%) | 2<br>(16%) | 2<br>(16%) | 2<br>(16%) | 2<br>(16%) | 2<br>(16%) |

Таблицадан күренгәнчә, бакчада тәҗрибәле белгечләр эшли. Ел дәверендә эш тәҗрибәсе әз булган педагогларга методик ярдәм күрсәтелде.




**Педагогларны аттестацияләү**

| уку елы | барлыгы | югары категорияле | I(беренче) категорияле | СЗД | категория-сезләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 2020-2021 | уку елының башы – 12 | 3 – 23% | 6 – 46% | 1 – 7,2% | 3<br>3% |
| | уку елының азагы – 11 | 3 – 25% | 6 – 50% | - | 2<br>16,6% |
| 2021-2022 | уку елының башы – 11 | 2 – 18% | 7 – 63% | 1 – 9% | 1<br>18% |
| | уку елының азагы – 11 | 2 – 18% | 7 – 63% | - | 1<br>9% |
| 2022-2023 | уку елының башы – 11 | 2- 18% | 8 – 73% | - | 1<br>9% |
| | уку елының азагы – 12 | 2 – 16,5% | 8 – 67% | - | 2<br>16,5% |



Педагогик квалификация күтәрү

Педагогик кадрларның квалификациясен күтәрү системасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең оештыру – методик эш планы белән каралган. Курсларны әзерләү педагогның һөнәри үсешенең аерылгысыз өлеше булып тора.

**2022-2023 елларда квалификация күтәрү курсларына 3 гариза кабул ителде.**

Җамиева Гюзәл Җәүдәт кызы – тәрбияче, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты "өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе , 15.05. – 27.05. 2023ел;
Галиуллина Динара Муллаян кызы – тәрбияче, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты "Казан педагогика көллияте", 03.04. – 15.04.2023 ел;
Хөснеева Элвира Әмир – музыка җитәкчесе, Казан (Идел буе) федераль университетының Психология һәм мәгариф институты мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм һөнәри әзерләү Идел буе төбәк-ара үзәге, 23.01. – 04.02. 2023 ел;
Нәтиҗә: бүгенге көндә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә яхшы мәдәни дәрәҗәгә ия профессиональ һәм белемле педагогик коллектив эшли. Педагоглар үз - үзләренә ышана, сыйфатлы нәтиҗә алуга мотивацияләнгән, эшчәнлеккә адекват бәя бирә.
Ел дәверендә педагоглар һәрдаим район һәм шәһәр күләмендә уздырылган семинарларда, методик берләшмә эшләрендә катнашып үз белемнәрен күтәрү өстендә эшләделәр.
Уку елы дәвамында безнең балалар бакчасы педагоглары район, шәһәр, Республика, регион һәм халыкара күләмендә эш тәҗрибәсе белән уртаклаштылар:

1. «Экологик күпер " темасына Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең өлкән тәрбиячеләре өчен муниципаль – ара семинар – практикум һәм экологик-агарту чаралары. Табигать белән дәвалау. Матурлык якын., 2022 елның 12 октябре Педагоглар: өлкән тәрбияче Морозова А.М., тәрбияче Бадертдинова А. Д.
2. Киров һәм Мәскәү районнары татар теле тәрбиячеләре өчен методик берләшмә – "Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үсеше бурычларын комплексны тормышка ашыру өчен сәнгати – эстетик үстерешле мохит оештыру", Казан шәһәре Киров районының "Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы, 27 нче октябрь 2022 ел.
Педагоглар: Гайнуллина А.Х.
3. Киров һәм Мәскәү районнары татар телендә өйрәтү тәрбиячеләре өчен методик берләшмә – "Татар халык иҗаты, әкиятләре аша балаларның сөйләм телен үстерү", Казан шәһәре Мәскәү районының "105 нче катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче балалар бакчасы", 18 нче ноябрь, 2022 нче ел.
Педагоглар: Шәйхетдинова Г. Г.
4. "Финанс грамоталылыгы нигезләре белән танышканда өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларда танып белү кызыксынучалыгын формалаштыру" темасына "танып белү үсеше"юнәлеше буенча Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнарының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләренең РМО кысаларында семинар-практикум, Казан шәһәре Мәскәү районының "184 нче катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирүче балалар бакчасы", 09 ноябрь 2022 ел.
Педагоглар: 184 нче балалар бакчасы педагоглары.

5. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм сәләтләрен үстерү шарты буларак сөйләм үстерүнең педагогик технологияләрен нәтиҗәле кертү" темасына педагоглар өчен зональ семианр – практикум, "Югары Ослан "Каенкай" балалар бакчасы " муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 2022 елның 29 ноябре.
Педагоглар:
6. Юлда куркынычсыз тәртип буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларда функциональ грамоталылык алшартларын формалаштыру буенча ата – аналар белән хезмәттәшлек итүнең актив формалары"

темасына Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары балалар бакчасы педагоглары өчен семинар – практикум, Казан шәһәре Киров районының "ЦРР-88 нче балалар бакчасы" МАДОУ, 2023 елның 26 гыйнвары.
Педагоглар: Өлкән тәрбияче Морозова А.М., тәрбияче Рахманова З.Н.

7. Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары укытучы – логопедларының "укытучы – логопедның коррекция эшендә нейропсихологик ысулларны һәм алымнарны куллану" темасына методик берләшмәсе, Казан шәһәре Мәскәү районы "Татар теле белән Кушма төрдәге 105 нче балалар бакчасы" МАДОУ, 2023 елның 27 гыйнвары
Укытучы-логопед: Хөснетдинова Д.Н.
8. "Социаль – коммуникатив, танып белү, физик, сөйләм, сәнгать – эстетик үсеш өлкәсендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның белем бирү эшчәнлеген оештыру" темасына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән тәрбиячеләре өчен семинар – практикум, Казан шәһәре Киров районының "комбинат төрдәге 288 нче балалар бакчасы" МАДОУ, 2023 елның 26 гыйнвары .
Педагоглар: Бадертинова А. Д., Зиялиева Г. Р., Морозова А. М., Хөснеева Э. А., Шәйхетдинова Г. Г.
9. Киров һәм Мәскәү районының татар төркемнәре тәрбиячеләре өчен методик берләшмә – “Фундаменталь грамоталылыкның алшартларын формалаштыру: финанс грамоталылыгы”, Казан шәһәре Киров районының “Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе, 14 нче март 2023 ел.
Педагоглар: Морозова А.М., Бадертинова А.Д., Гайнуллина А.Х.

**Безнең педагоглар да күп кенә бәйгеләрдә катнаштылар:**

1. Район конкурсы “Үз кулларың белән китап Э.Н. Успенский әсәрләренә заманча караш”, 3 урын өчен диплом, педагоглар: Бадертдинова А. Д., Морозова А. М., Рахманова З. Н., Хөснетдинова Д. Н., Шәйхетдинова Г. Г.
2. "Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен иң яхшы интерактив уен" район конкурсы, диплом "иң яхшы интерактив уен" номинациясе, педагог: Бадертдинова А. Д.
3. "Татар язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләренә заманча караш" район конкурсы, 2 нче урын өчен диплом, педагоглар: Гайнуллина А. Х., Зиялиева Г. Р., Морозова А. М., Шәйхетдинова Г. Г., Рахманова З. Н., Жамиева Г. Д.
4. "Белем бирү учреждениесенең Видео визиткасы: Казан шәһәре мәктәпкәчә белем бирү" шәһәр конкурсының район этабы, катнашу өчен диплом, педагоглар: Литвинова Э. Ф., Морозова А. М., Шәйхетдинова Г. Г.

**Безнең балалар да күп кенә бәйгеләрдә катнаштылар:**

1. Мәктәпкәчә яшьтәге һәм 1-6 сыйныф укучылары өчен "Хат сере" республика иҗади конкурсы, "Республика олимпиада үзәге" ГАОУ җиңүчесе дипломы, 1.10.2022 24.10.2022 елгы 92 – 1 од номерлы Боерык. Шавалева Самира.
2. "Эколатлар – яшь табигать саклаучылар бәйрәме" бөтенроссия (халыкара) фестиваленең район этабы "мастер –класс" номинациясе, 3 урын өчен диплом, 05.10.2022 ел, № 326 боерык. Тәрбияләнүчеләр: Шавалиева Самриа, Белова Екатерина, Маслова Василиса.
3. Махсуслаштырылган балалар бакчалары һәм компенсацияләү юнәлеше төркемнәре тәрбияләнүчеләре өчен шәһәр конкурсының район этабы" һәр баланың уңышы "номинациясе" балалар рәсеме, аппликация", 1 урын өчен диплом, 23.11.2022 №411 боерыгы. Салаватуллин Руслан.
4. Сөйләм һәм вокал сәнгатенең Халыкара онлайн конкурс – фестивале, РФ МК, МОиНРТ, ТР МК, мәдәният институтының 1 дәрәҗә дипломы театр, кино һәм телевидение факультеты,

театр иҗаты кафедрасы, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге, "Татнетны үстерү фонды" коммерцияле булмаган оешмасы, 2022 ел, Садыйкова Айша Илшат кызы.

5. "Бозда һәм суда уяу булачакмын" Республика конкурсының район этабы, 3 урын өчен диплом ,14.11.2022 ел, №398 боерык. Тәрбияләнүче: Нехорошков Павел.
6. "Туган телем – серле тел" төбәкара укучылар конкурсы "Татар теле" номинациясе яшь категориясе мәктәпкәчә яшь, 2 дәрәҗә диплом " В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП), 13.02.2023 №52 боерык. Садыкова Айша.
7. Балалар куркынычсызлыгы буенча район агитация видеороликлары конкурсы «Куркынычсыз балачак «номинациясе "Хәвефсез йорт", 1 урын өчен диплом, 07.12.2022 № 433 боерык. Семикозова Есения.
8. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен республика олимпиадасы "Галим бала", III дәрәҗә диплом ГАОУ Республика олимпиада үзәге, 28-29.01.2023 боерык no 15 – 1/ 23 20.02.2023 елгы од. Мазитова Алия.
9. Республика балалар һәм яшүсмерләр театрлары фестиваленең район этабы, катнашуы өчен диплом, 14.10.2022 № 345 боерык. Педагоглары: Морозова А. М., Хөснеева Э. А., Шәйхетдинова Г. Г.
10. "Йолдыз бул – 2023" балалар талантлары фестиваль конкурсында җиңүче дипломы, Ярмиева Әминә, педагог: Хөснеева Э.А., 2023 ел.
11. Кече мәктәп укучыларының балалар спектакльләре видеофильмнары онлайн-конкурсы "Исәнме, балалар театры", 3 урын өчен Мактау грамотасы, КДУ Психология һәм мәгариф институты, педагоглар: Морозова А. М., Бадертинова А. Д., Шәйхетдинова Г. Г., Хөснеева Э. А

**2021 – 2022 нче уку елында балалар бакчасында инновацион мәйданчык статусы бирелде:**

Казан шәһәре мәгариф оешмаларында инновацион проектларны гамәлгә ашыру турында 2021 нче елның 29 нчы октябрендәге 906 номерлы боерык нигезендә балалар бакчасына инновацион мәйданчык статусы бирелде. Инновацион эшнең темасы: "Балалар бакчасында фундаменталь грамоталылык алшартлары формалаштыру". Балалар бакчасында бу юнәлеш буенча 2022 – 2023 нче уку елларында, ел дәверендә педагоглар тарафыннан эш алып барылды.

Безнең балалар бакчасында 2022 нче елның 09 ноябрендә "Финанс грамоталылыгы нигезләре белән танышканда өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларда танып белү кызыксынучалыгын формалаштыру" темасына "танып белү үсеше"юнәлеше буенча Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнарының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләренең РМО кысаларында семинар-практикум оештырылды. Шулай ук, безнең балалар бакчасы педагоглары Казан шәһәре Киров районының "Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе, 14 нче март 2023 елда оештырган "Фундаменталь грамоталылыкның алшартларын формалаштыру: финанс грамоталылыгы", дип аталган методик берләшмәдә үз эш тәҗрибәләре белән бүлештеләр, актив катнаштылар. Методик берләшмәдә катнашкан педагоглар:Морозова А.М., Бадертинова А.Д., Гайнуллина А.Х.

Барлык уздырылган чаралар зур бәягә лаек булды, тәрбиячеләрнең профессиональ дәрәҗәләрен, яхшы теоретик һәм практик белемнәрен һәм осталыкларын билгеләп үттеләр.

Педагогик тәҗрибәнең дәрәҗәсе һәм нәтиҗәлелеге

| Педагогик эш тәҗрибә белән уртаклашу: | Чыгышлар | | | Бәйгеләр | | | Публикацияләр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2020 - 2021 | 2021 - 2022 | 2022 - 2023 | 2020 - 2021 | 2021 - 2022 | 2022 - 2023 | 2020 - 2021 | 2021 - 2022 | 2022 - 2023 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Район өлкәсендә | 7 | 4 | | 11 | 14 | | | 1 | |
| Шәһәр өлкәсендә | | 1 | | | 1 | | | | |
| Республика дәрәҗәсендә | | 2 | | 6 | 1 | | | 1 | |
| Бөтенроссия дәрәҗәсендә | | | | 3 | 1 | | | | |
| Халыкара дәрәҗәсендә | 2 | | | 4 | 4 | | 5 | 4 | |

Безнең коллектив киләчәктә дә педагогларның методик берләшмәләрендә актив катнашырга, профессиональ осталык һәм автор программалары бәйгеләрендә катнашу өчен педагогларның иҗади сәләтләре белән уртаклашырга, фикерләшергә планлаштыра.

Балалар бакчасындагы барлык хезмәткәрләр 2022-2023 нче уку елына карата кабул ителгән еллык эш планына, муниципаль заданиегә, район мәгариф бүлеге һәм методик берләшмә планына нигезләнеп тәрбия-белем бирү эшен алып барды.

**2022 - 2023 нче уку елында балалар бакчасының методик темасы:**

**Балалар бакчасының төп максаты:**

Балалар бакчасының төп юнәлеше: милли йолалар һәм гореф гадәтләргә таянып күпкырлы шәхес тәрбияләү.

**Балалар бакчасының төп бурычлары:**

1. Милли традицияләргә нигезләнеп, балаларга милли тәрбия бирүне камилләштерү.
2. Экологик тәрбия аша табигатьне ярату, туган якка ихтирам, горурлык хисләре, сакчыллык тәрбияләү.
3. Функциональ грамоталыкның алшартларын формалаштыру: балалар бакчасында финанс грамоталыгын үстерү буенча эшне камилләштерү.

2022 - 2023 уку елы дәверендә балалар бакчасы педагоглары Федераль дәүләт белем бирү стандартын исәпкә алып эш итүне дәвам иттеләр. ФДБС хәзерге заманда бик тә актуаль булган укыту-тәрбия системасын яңарту буенча тәрбиячеләрнең белемнәрен киңәйтү һәм системалаштыру өчен иҗади төркем актив эш алып барды. Проблеманы теоретик яктан өйрәнү белән беррәттән аны практикада да актив кулландылар.

Тәрбиячеләр көндәлек тәрбия-белем бирү планын Федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм яңа СанПиН таләпләренә туры китереп яздылар. Эшләрендә төрле ысуллар һәм чаралар куллансалар да, аларның барысы да үсеп килүче шәхеснең төрле яктан үсешен булдыруга юнәлтелгән. Танып белү мәсьәләләре төрле төр эшчәнлек вакытында чишелә: уен, үзара аралашу дәверендә, продуктив эшчәнлектә, физкультура сәламәтләндерү чаралары уздыруда h.б.

**Еллык планда каралган бурычларның беренчесе** – Милли традицияләргә нигезләнеп, балаларга милли тәрбия бирүне камилләштерү.

Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру ─ хәзерге буынның төп вазифасы. Күңелендә аз гына милли хисе булган кеше дә моңа битараф кала алмый торгандыр. Ана теле - сабыйларга аң-белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә.

Соңгы елларда, милли хисләр тәрбияләү проблемасы кисәк кенә калкып чыкты. Хәзерге чорда радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, рухына әдәпсезлек үрнәкләрен сеңдергән заманда, милләтнең гасырлар буе формалашкан тәҗрибәсе, әхлак кагыйдәләре югала бара. Менә шуның өчен дә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә нәниләргә халкыбыз хәзинәләре нигезендә милли үзаң тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирелергә тиеш.

Милли үзаңны үстерү бурычларын гамәлгә ашыру өчен, педагогик эшне ачык максатлар куеп, фәнни нигездә оештыру, белем-тәрбиянең эчтәлеген, метод һәм чараларын дөрес итеп билгеләү сорала.

Бу юнәлештәге түбәндәге эшләр планлаштырылды һәм тормышка ашырылды:

1. 01.-9.2022 нче елны “Яңа уку елы” – методик берләшмә уздырылды. Методик берләшмәнең максаты булып 2022 – 2023 нче уку елында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү учреждениесе эшенең төп юнәлешләрен билгеләү.
2. 31.10.2022 нче ел “Татар халык мәкальләре аша балаларның сөйләм телен үстерү” дигән темага косультация уздырылды. Төркем тәрбиясече Гөлшат Равил кызы Зиялиева әзерләде.
3. 24.10.2022 нче елда мәктәпкә әзерлек төркемендә “Йомры икмәк” – әсәре буенча театр күрсәтелде. Театр өстендә төркем тәрбиячесе Бадертдинова Алсина Дамир кызы, татар теле тәрбиячесе Шәйхетдинова Гөлназ Габдулла кызы, музыка җитәкчесе Хөснеева Элвира Әмир кызы.
4. 24.10 . – 28.10 2022 кадәр балалар бакчасында әата – аналар өчен “Ачык ишекләр атналыгы” уздырылды. Расланган план буенча атна дәверендә төркем тәрбиячеләре, белгечләр әти – әниләрне кабул иттеләр. Ата – аналарга шөгыльләр, шәхси консультацияләр уздырылды. Милли тәрбия бирү буенча чаралар уздырылды.
5. 20.01.2023 нче ел “Әдәп төбе – матур гадәт” – дигән темага төркемтәрбиячесе Айзаря Хаҗинур кызы Гайнуллина консультация уздыры.
6. 21.02.2023 нче ел халык – ара туган телләр көне (күңел ачу кичәсе) уздырлды.
7. 26.04. 2023 нче ел “Тукай безнең күңелләрдә” тематик кичә уздырлды.
8. 17.04 – 28.04.2023 елга кадәр Габдулла Тукай әсәрләре буенча рәсем күргәәмәсе оештырылды.
9. Ел дәверендә балалар бакчасы район, шәһәр, республика күләм уздырылган бәйгеләрдә катнашып призлы урыннар яуладылар.

Еллык планда каралган бурычларның икенчесе - Экологик тәрбия аша табигатьне ярату, туган якка ихтирам, горурлык хисләре, сакчыллык тәрбияләү.

Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Һәр гамәлне акыл белән башкарырга кирәк, шул чакта гына без матурлыкны табигатьне коткарып кала алабыз. Табигать белән элемтәгә керү, күзәтү, хезмәт, уен, сәнгать эшчәнлеге аша тагын да белемнәрен ныгыту – бу экологик белемне күтәрүнең төп ачкычы.

Бу юнәлештәге түбәндәге эшләр планлаштырылды һәм тормышка ашырылды:

1. 21.11.2022 нче ел “Кече яшьтәге балалар белән эшләгәндә бала үсешенә уңай йогынты ясауда әйләнә – тирә мөхитне дөрес итеп оештөру” семинар – практикум уздырылды.
2. 26.12.2022 нче ел “Балалар бакчасында экологик тәрбия” дигән темага тәрбияче Гюзәл Җәүдәт кызы Җамиева консультация уздырыды.
3. “Аерым чүп җыю – безнең сайлау”, “Бергә үсәбез” проектлары буенча отчетлар ясалды.
4. 13.02. – 17.02.2023 нче ел “Без янгын сүндерүчеләр” – янгын куркынычсызлыгы атналгы кздырылды. (Уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) катнашты.
5. 20.02 – 28.02.2023 нче ел “Без янгын сүндерүчеләр” рәсем күргәзмәсе оештырылды.
6. 13.03. – 17.03.2023 “Балаларга хезмшт тәрбияче бирү” – дигән темага Гөлшат Равил кызы Зиялиева консультация уздырды.
7. Ай дәвамында “Кошларны каршылау” дип аталган тематик көннәр уздырылды.
8. 10.04 – 14.04.2023 нче ел “Шырпы белән уйнама!” рәсем күргәзмәсе оештырылды.
9. Ел дәверендә балалар бакчасы район, шәһәр, республика күләм уздырылган бәйгеләрдә катнашып призлы урыннар яуладылар.

4. Еллык планда каралган бурычларның өченчесе **-** Функциональ грамоталыкның алшартларын формалаштыру: балалар бакчасында финанс грамоталыгын үстерү буенча эшне камилләштерү.

Уку елына куелган бурычны тормышка ашыру буенча түбәндәге эшләр планлаштырылды һәм тормышка ашырылды:

**2021 – 2022 нче уку елында балалар бакчасында инновацион мәйданчык статусы бирелде:**

Казан шәһәре мәгариф оешмаларында инноваөион проектларны гамәлгә ашыру турында 2021 нче елның 29 нчы октябрендәге 906 номерлы боерык нигезендә балалар бакчасына инновацион мәйданчык статусы биреле. Инновацион эшнең темасы: “Балалар бакчасында фундаменталь грамоталылык алшартлары формалаштыру”. Балалар бакчасында бу юнәлеш буенча 2022 – 2023 нче уку елларында, ел дәверендә педагоглар тарафыннан эш алып барылды.

Безнең балалар бакчасында 2022 нче елның 09 ноябрендә "Финанс грамоталылыгы нигезләре белән танышканда өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларда танып белү кызыксынучалыгын формалаштыру" темасына "танып белү үсеше"юнәлеше буенча Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнарының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләренең РМО кысаларында семинар-практикум оештырылды. Шулай ук, безнең балалар бакчасы педагоглары Казан шәһәре Киров районының “Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе, 14 нче март 2023 елда оештырган “Фундаменталь грамоталылыкның алшартларын формалаштыру: финанс грамоталылыгы”, дип аталган методик берләшмәдә үз әә тәҗрибәләре белән бүлештеләр, актив катнаштылар. Методик берләшмәдә катнашкан педагоглар:Морозова А.М., Бадертинова А.Д., Гайнуллина А.Х.

Шулай ук ел дәвамында 2022 – 2023 нче уку елына төзелгән планга таянып балалар бакчасында төрле чаралар уздырылды.

1. 24.10 . – 28.10 2022 кадәр балалар бакчасында әата – аналар өчен “Ачык ишекләр атналыгы” уздырылды. Әти – әниләр инновацион проектны гамәлгә ашыру буенча эш торшы белән таныштылар.
2. 17.10.2023 нче ел “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның финанс грамоталыгын тәрбияләү нигезләре”дигән темага тәрбияе Зәйтүнә Наджим кызы Рахманова консультация уздырды.
3. 29.03.2023 нче ел “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда икътисадый категорияләр турында беренчел икътисадый күзаллаулар формалаштыру” – дигән темага педагогик киңәшмә уздырылды.
4. Инновацион проект буенча видео отчет әзерләнде

Шулай ук, балалар бакчасы педагоглары район, республика күләмендә уздырылган методик берләшмәләрдә катнашты.

**Белем бирү программасын үзләштерү дәрәҗәсе**

| Дәрәҗә | Югары | | Уртача | | Түбән | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Өлкәләр | сентябрь | апрель | сентябрь | апрель | сентябрь | апрель |
| “Социаль – коммуникатив үсеш” белем өлкәсе буенча күрсәткечләр | 23% | 77% | 63% | 18% | 5% | 0,5% |
| “Физик үсеш” белем өлкәсе буенча күрсәткечләр | 40% | 60% | 54% | 33% | 4% | - |
| “Танып – белү үсеше” белем өлкәсе буенча күрсәткечләр | 27% | 72,3% | 64% | 27,2% | 9% | 0,5% |
| “Сөйләм үсеше” | 32% | 74,2% | 56% | 23,8% | 12% | 2% |
| “Нәфис эстетик үсеш” белем өлкәсе буенча күрсәткечләр | 26% | 73% | 65% | 27% | 9% | - |

Ел ахырына Программаны үзләштерү мониторингы нәтиҗәләре күрсәткәнчә, төрле яшьтәге төркем балалары материалның югары һәм урта дәрәҗәдә үзләштерелгән. Ел дәвамында педагогларның белем бирү эшчәнлегендә, балалар мөстәкыйль эшчәнлеген оештыруда, индивидуаль эш алып баруда планлы максатчан эш алып барулары нәтиҗәсендә ел азагында инде тагын да югарырак нәтиҗәләргә ирешеп була.

Тәрбия-белем бирү процессының сыйфат күрсәткечләренең берсе-мәктәпкәчә яшьтәге балаларда уку эшчәнлегенә алшартлар тудыру. Балалар бакчасы һәм мәктәп, педагог-психолог арасында дәвамчанлык

кысаларында ел саен әзерлек төркемнәре балалары өчен тест үткәрелә. Балалар бакчасында коррекция эшләре белән психологик һәм логопед хезмәтләре шөгыльләнә. Аларның бурычына сөйләмдәге җитешсезлекләрне бетерү һәм төзәтү, балаларның психик сәламәтлегендә авыр сөйләм патологиясен һәм тайпылышларны иртә диагностикалау һәм профилактикалау, пмпкга документлар рәсмиләштерү, балаларның мәктәпкә әзерлеген диагностикалау, шулай ук педагогларга һәм ата-аналарга консультация ярдәме керә.

Нәтиҗә: программа бүлекләре буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагогик коллективының эшен анализлау күрсәткәнчә, оештырылган белем бирү эшчәнлеген, күңел ачу, уеннарны даими, системалы рәвештә үткәрү, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның белемнәрен киңәйтә һәм тирәнәйтә торган төрле технологияләрне, проект методын һәм алымнарны куллану төрле яшьтәге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып-белү өлкәсен диагностик тикшерү нәтиҗәләрен арттыралар. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләрнең иҗади сәләтләрен ачуга, танып – белү эшчәнлегенә зур кызыксынуга ия булган тәрбияләнүчеләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрелә.

Балаларны мәктәпкә хәзерләү, уку эшчәнлеге белән кызыксыну һәм мәктәптә укыйсы килү теләге уяту эше ел дәверендә алып барылды.

Уку елы дәверендә бакча ГБМБУ «КФУ каршындагы 2 нче татар гимназиясе» һәм ГБМБУ «Г.Ибрагимова исемендәге 17 нче татар гимназиясе» белән тыгыз элемтәдә эшләде. Бергә оештырылган җыелышлар, семинарлар, күңел ачу һәм спорт кичәләре, үзара дәресләрдә булу, чыгышлар ике як педагоглары өчен дә бик файдалы булды.

Психолог Идрисова Инна Вениаминовна уздырган диагностика буенча мәктәпкә әзерлек төркем балаларының мәктәпкә әзерлек дәрәҗәсе: мәктәпәкә әзерлек төркеме № 03 нче төркем балалары. 2023 нче елның апрель аенда уздырылган диагностикада барлыгы 16 бала катнашты.

Югары – 9 бала (56%)
Уртача – 7 бала (44%)
Барлыгы – 16 бала

Бакчада катнаш логопедия төркеме эшләп килә. Балаларның сөйләмдәге кимчелекләрен төзәтү буенча укытучы-логопед Хөснетдинова Д. Н. уңышлы гына эшләде. Ул үз эшчәнлеген 3 юнәлештә – тәрбия, үсеш, белем бирү юнәлешендә алып барды.  16 баланың 7 – өлкәннәр, 8 – мәктәпкә әзерлек төркеменнән, 1 – уртанчылар төркеменнән. ФФН – 1 бала. ОНР – 15 бала.

Ел дәверендә алып барылган эшкә карап май аенда булган ПМПК бәя бирде: мәктәпкә әзерлек төркеменнән чыгарылган 5 чыгарылды. 3 бала яхшы (чиста) сөйләм белән  чыгарылды, 2 се зур үзгәрешләр белән чыгарылды.

Бакча татар телендәге тәрбия-белем бирү учагы буларак, эшебезнең төп юнәлеше – туган төбәкне өйрәнеп, халкыбызның гасырлар буена тупланып килгән мирасын, күңел бизәкләренең матурлыкларын балаларга җиткерү, сабыйларда милли мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү, ана теленә карата мәхәббәт тәрбияләү. Татар теле тәрбиячесе Шәйхетдинова Г.Г. һәм тәрбиячеләр милли бәйрәмнәребез турында белем бирүне максат итеп алып «Сөмбелә», «Нәүрүз», «Карга боткасы», “Сабантуй” бәйрәмнәре үткәрделәр.

Уку елы дәвамында балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү эше алып барылды. Балалар белән оештырылган эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш,  аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычлары буенча эш алып барылды.

Балаларга туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү һәм татар телен УМК кулланып үзләштерү буенча түбәндәге эшләр планлаштырылды һәм тормышка ашырылды:

1. “Йомры икмәк” (УМК) әсәрен сәхнәләштреү.
   Әкиятләр сәхнәләштерү.
2. Туган тел айлыгы.
3. Г.Тукай әсәрләре буенча күргәзмә.
4. Ай саен “Татар телен саклау һәм популярлаштыруда УМК куллану” темасына педагогик сәгать үткәрелде.
5. Татар теле тәрбиячесе Шәйхетдинова Г.Г. “УМК кулланып балаларны ике телгә өйрәтүдә яңа караш” һәм “Татар телендәге мультфильмнарга таянып балаларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү” темасына әти - әниләр җыелышларында чыгышлар ясады.
6. Тәрбиячеләр әти - әниләр почмагында  УМК турында мәгълүматны яңартып тордылар.
7. Сабантуй бәйрәме.

8. Бәйгеләр уздыру:
- Шигырь бәйгесе уздыру (татар һәм рус телендә шигырьләрне сәнгатьле итеп яттан сөйләү);

9. Балаларны туган телне үзләштерү буенча сөйләм күрсәткечләре (зурлар төркеме) – 16.01 – 20.01.2023 ел.

Шулай ук милли балалар фольклорын һәр шөгыльдә кулланалар, балалар белән халкыбызның милли уеннарын уйныйлар.

Ел дәвамында, эшчәнлек барышында һәм шәхси эш вакытында файдаланган УМК буенча эш балаларның татар телендә аралашуларына һәм туган тел турында мәгълүмат туплауларында зур ярдәмлек булды. Уку елы ахырында уздырылган диагностик күзәтүләр буенча балаларның татар телдә бәйләнешле сөйләм дәрәҗәсе түбәндәгечә булды:

Уртанчылар төркеме (02 нче төркем) – 77%,

Зурлар төркеме (03 нче төркем) – 80%,

Мәктәпкә әзерлек төркеме (05 нче төркем) –84 %.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шарты булып тора. Шуңа да УМК кулланып балаларга дәүләт телләрен өйрәтүдә гаилә һәм белем бирү учреждениясенең узара эшчәнлеген системалаштыру бик мөхим.

Тәрбия-белем бирү эше уңышлы һәм нәтиҗәле булсын өчен гаилә һәм балалар бакчасының алып барган тәрбияви чаралары да бер-берсенә теләктәшле булырга тиеш, бер үк максатка омтылган булуы кирәк. Бакчаның, гаиләнең бердәм эш итүе баланың һәркайда, һәрбер урында бер үк төрле, бер-берсенә каршы булмаган теләкләр кую зарурлыгын күрсәтә. Бу эшне без әти-әниләр белән эшләүнең төрле формаларын, оештыру чараларын файдаланып тормышка ашырдык. Әти-әниләр белән берлектә оештырылган гомуми җыелышлар, түгәрәк өстәлләр, очрашулар, бәйрәмнәр, бәйгеләр безнең барыбызга да файдалы узды.

3 айга бер уздырыла торган “Ачык ишекләр көне” әти-әниләрнең үз балаларының көндәлек тормышлары турында тулырак мәгълүмат биреп килде.

Әти-әниләр белән эшнең нәтиҗәле булуын әти-әниләр бердәмлеге оештырды. Алар бу уку елы дәверендә бакча хезмәткәрләре белән бергә ремонтлар ясарга, уенчыклар алырга, уеннар ясауда, бәйрәм аттрибутлары булдыруда бик актив катнаштылар. Бакчабызда аларга рәхмәт хисләрен белдереп торабыз.

Бакчабыз автономия режимында эшләүне дәвам итте. Күзәтүчеләр оешмасы (Наблюдательный Совет) утырышлары план буенча уздырылып килә, анда башкарылган эшләрне, киләчәккә планнарны һәм шул планнарны ничек итеп тормышка ашыру мөмкинлекләрен сөйләшәбез, тәкъдимнәр һәм җитешсезлекләрне уйлашабыз.

Административ хуҗалык эшләре бакчаның үсеш планы, еллык план буенча һәм аннан тыш башкарылды**.** Музыка залына һәм коридорларда ремонт ясалды.

Җылылык системасына кышкы һәм язгы вакытына опрессовкалар уңышлы уздырылды.

Төркемнәрдә санитария-гигиена таләпләрен үтәү өчен барлык шартларны тудыру өстендә һәрдаим эш алып барылды. Барлык төркемнәр савыт – сабалар тәэмин ителүе өстендә хуҗалык эшләре буенча мөдир Гимадеева Г.И. зур тырышлык күрсәтте.

Узган уку елында башкарылган эшләр буенча түбәндәге ***нәтиҗәләр*** ясала:

1) ел башында алга куелган барлык бурычларны башкару юнәлешендә барлык хезмәткәрләр төрле формалар, чаралар һәм алымнар кулланып уңышлы рәвештә хезмәт иттеләр;

2) бакча белән җитәкчелек итү Уставка таянып алып барыла, эшчәнлеге – тәрбия-белем бирү процессы 2022-2023 нче уку елына карата кабул ителгән еллык эш планына, муниципаль заданиегә, район мәгариф бүлеге һәм методик берләшмә планына нигезләнеп алып барылды;

3) балалар бакчасында укыту-тәрбия эше Федераль Дәүләт Белем Стандартлары буенча башкарылды;

4) уку елы дәвамында балаларны туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү һәм татар телен үзләштерү эшчәнлегендә УМК файдаланылды.

5) Балалр бакчасында түләүле түгәрәкләр 2022 нчы елның сентябрь аеннан оештырылды.

Ирешелгән нәтиҗәләр һәм булган проблемаларны, җитешсезлекләрне искә алып бакча хезмәткәрләре яңа уку елында алга түбәндәге максатларга ирешергә тиеш:

* укыту-тәрбия эшен Федераль Дәүләт Белем Стандарларына таянып тормышка ашыру;

* администрация тарафыннан дөрес тукلануны контрольдә тоту;
* балаларның сәламәтлеген саклау буенча эшне дәвам итү.

**2023-2024 нче уку елына**

Балалар бакчасының төп юнәлеше: милли йолалар һәм гореф гадәтләргә таянып күпкырлы шәхес тәрбияләү.

**<u>Балалар бакчасының төп бурычлары:</u>**

1. Милли традицияләргә нигезләнеп, балаларга милли тәрбия бирүне камилләштерү.

2. Театральләштерелгән эшчәнлек аша мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен камилләштерү.

3. Функциональ грамоталылыкның алшартларын формалаштыру: балалар бакчасында финанс грамоталылыгын үстерү буенча эшне камилләштерү.

## 4. КАДРЛАР БЕЛӘН ЭШ

**1.1 Аттестация**

**Педагогик кадрларны аттестацияләү.**
**АТТЕСТАЦИЯ ПЕДАГОГИЧЕСКИХ КАДРОВ**

***2023 – 2024*** **нче уку елында түбәндәге педагоглар аттестациягә әзерләнәләр** :

1. ***Рахманова Зәйтүнә Наджим кызы- тәрбияче, беренче квалификацяле категория;***

**Аттестациягә баручы педагоглар белән эш планы**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| **1.** | Аттестация үтүче педагоглар списогын яңарту. | Сентябрь | Өлкән тәрбияче |
| 2. | Педагогларның гаризаларын һәм аттестацион материалларын карап үтү | Сентябрь-октябрь | мөдир<br>Өлкән тәрбияче |
| 3. | Педагогларның аттестация үтү буенча эш документлары белән таныштыру. | октябрь | Өлкән тәрбияче |
| 4. | Педагогларны квалификацион сынауга әзерләү . | Кварталга 1 | Өлкән тәрбияче |
| 5. | Педагогларның иҗади лабораторияләрен, эш документацияләрен тикшерү | Октябрь | Өлкән тәрбяиче |
| 6. | Аттестация материалларын мәктәпкәчә мәгариф идарәсенә тапшыру . | Декабрь | Мөдир,<br>Өлкән тәрбияче |

## 1.2 ИНСТРУКТАЖЛАР. ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ. ПРОИЗВОДСТВО ҖЫЕЛЫШЛАРЫ. ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЧЕ ПЕРСОНАЛ ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯ

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Куркынычсызлык техникасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы буенча агымдагы инструктажлар үткәрү. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, завхоз |
| 2 | Производство җыелышы: | | Бакча мөдире |
| | **а) «Хезмәтне оештыру кагыйдәләре»** | сентябрь | |
| | б) «Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре» | Май | Бакча мөдире |
| 3 | Хезмәтне саклау комиссиясе рейдларын үткәрү (3-х ступенчатый контроль) | Август,январь | Бакча мөдире, өлкән шәфкать туташы завхоз, профком |
| 4 | Гражданлык оборонасы буенча хезмәткәрләр һәм балалар белән эвакуацияләү тренировкалары үткәрү | квартал саен | Бакча мөдире, завхоз |
| 5 | Яңа ел чыршы бәйрәмен үткәргәндә техник һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлеше | декабрь | Бакча мөдире, завхоз |
| 6 | Медицина күзәтүен, диспансеризация тикшерүен үтүне оештыру | график буенча | Бакча мөдире, шәфкать туташы |
| 7 | Хезмәткәрләрне спецкиемнәр һәм юу чаралары белән тәэмин итү | ел дәвамында | Бакча мөдире, завхоз |

## 1.3 Гомуми хезмәт коллективы җыелышлары

| № | Эшнең эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | **Яңа уку елына бурычлар**<br>*Җәйге сәламәтләндерү чоры нәтиҗәләре.<br>*Яңа уку елына әзерлек акты белән танышу.<br>*Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре елән танышу.<br>*Аттестациягә әзерлек. | Сентябрь | Мөдир,<br>өлкән тәрбияче,<br>тәрбиячеләр,<br>белгечләр. |
| 2 | **Уку елының 1 яртыеллыгына анализ**<br>*Укыту- тәрбия эшләренә анализ. Яңа елга әзерлек. Җаваплы кешеләр билгеләү.<br>*Бәйрәм көннәренә дежурлык графигы белән таныштыру.<br>*Административ – хуҗалык эшләренә анализ.<br>*Балаларны сәламәтләндреү сыйфатына анализ.<br>* Хезмәт дисциплинасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре елән танышу.<br>*Отпуск графины төзү. | Декабрь | Мөдир,<br>өлкән тәрбияче,<br>тәрбиячеләр,<br>белгечләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | **Уку елының 2 яртыеллыгына анализ**<br>*Укыту- тәрбия эшләренә анализ.<br>*Административ – хуҗалык эшләренә анализ.<br>*Балаларны тукландыру сыйфатына анализ<br>*Җәйге сәламәтләндреү чорына әзерлек, җәйге план проекты белән танышу.<br>*Яңа уку елына бурычлар. | Май | Мөдир,<br>өлкән тәрбияче,<br>тәрбиячеләр,<br>белгечләр. |

## 1.4 ПЕДАГОГИК ОЕШТЫРУ ЭШЛӘРЕ

### Педагогик киңәшмәләр

**I - киңәшмә (Август)**
**“Яңа уку елы”**

1.Төркемнәрнең яңа 2023- 2024 нче уку елына әзерлеген тикшерү.
(Бакча мөдире Литвинова Э.Ф.)
2.Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән уртак эшчәнлекне оештыруны тематик планлаштыру.
(Бакча мөдире Литвинова Э.Ф.)
3.Укыту – тәрбия процессын оештыру һәм яңа уку елына балалар белән эшләү өчен шартлар тудыру (2023 – 2024 уку елына оештырылган белем бирү эшчәнлегенең уку планнары, белгечләр эше, түгәрәкләр эше).
(Бакча мөдире Литвинова Э.Ф.)
4.Яңа уку елына төзелгән эш планын раслау:
2023 – 2024 нче уку елына төзелгән: комплекслы – темтик планнар, шөгыльләр челтәрен, белгечләрнең циклограммаларын;
5.Салкын вакыт өчен төзелгән режимны, балалар бакчасы эшләячәк программаны;
6.Өстәмә түләүле түгәрәкләр оештыру буенча эшчәнлекне раслау;
7.Еллык планның үтәлешен анализлау;
8.2023- 2024 уку елына эш планы проекты белән таныштыру;
9.Хезмәттәшләрнең эш графигын раслау
10.Төрле мәсьәләләр.

**<u>II –киңәшмә (Декабрь)</u>**

**Федераль дәүләт белем бирү стандартларын исәпкә алып заманча мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә театральләштерелгән эшчәнлек.**

1. Кереш сүз. Балалар бакчасында театр эшчәнлегенең мәгънәсе һәм үзенчәлеге.
   (мөдир Литвинова Э. Ф.)
2. Беренче педагогик киңәшмә карары буенча хисап.
   (өлкән тәрбияче Морозова А.М.)
3. «Театральләштерелгән эшчәнлек чарасы буларак актерлык осталыгы элементлары белән сәхнә сөйләме буенча тренинглар» эш тәҗрибәсе белән уртаклашу.
   ( тәрбияче Зиялиева Г.Р., музыка җитәкчесе Хөснеева Э.А.)
4. Нәтиҗә ясау, педагогик совет карары кабул итү.
   (мөдир Литвинова Э.Ф.)

**<u>III-киңәшмә (Март)</u>**

«Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның финанс грамоталылыгы нигезләрен формалаштыру чарасы буларак икътисади тәрбия»

1.Узган педсовет карарын үтәү турында хисап. (мөдир – Литвинова Э.Ф.)
2. "Балаларны финанс грамоталылыгына өйрәтүдә педагогик компетентлык дәрәҗәсен күтәрү". (өлкән тәрбияче – Морозова А.М.)

3. “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда финанс грамоталылыгын формалаштырганда нәфис әдәбиятны куллану". (тәрбияче – Жамиева Г.Д.)
4. “Уен эшчәнлегендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның финанс грамоталылыгы нигезләрен формалаштыру". (тәрбияче – Рахманова З.Н.)
5. “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда финанс грамоталылыгын формалаштыру эшен оештыру " тематик контроль нәтиҗәләре” (өлкән тәрбияче – Морозова А.М.)

**IV –киңәшмә (Май)**

**Ел йомгаклары буенча**

1. Еллык педагогик эшчәнлеккә анализ.
( мөдир Литвинова Э.Ф.)
2.Инновация эшчәнлеге торышы, нәтиҗәләре.(Морозова А.М.)

3. Чыгарылыш төркеме балаларының мәктәпкә әзерлеге турында мәглүмат. (Тәрбияче: Загидуллина А.Д.)

4. а) Балалар белән уздырылган чыныктыру – сәламәтләндерү чараларына, балаларның авырып калдырган көннәренә анализ.
б) Җәйге сәламәтләндерү планын раслау.
(шәфкать туташы: Алимпиева Л.Г.)
5. Җәйге сәламәтләндерү планы белән таныштыру.(өлкән тәрбияче Морозова А.М.

### 5.1 ТӘРБИЯЧЕЛӘР ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплыкешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | «Туган телне өйрәнүдә балалар фольклорының роле. Әкиятләр» | Октябрь | Шайхутдинова Г.Г. |
| 2. | «Балалар бакчасында театральләштерелгән эшчәнлекне оештыру һәм үткәрү методикасы» | Декабрь | Хөснеева Э.А. |
| 3. | «Сәламәт булыйм дисәң» | Гыйнвар | Набиуллина В.Н. |
| 4. | «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда финанс грамоталылыгын тәрбияләү буенча эш формалары һәм ысуллары» | Март | Рахманова З.Н. |
| 5. | «Җәйге сәламәтләндерү чорында эшне оештыру» | Май | Морозова А.М. |

### 5.2 СЕМИНАР-ПРАКТИКУМНАР

| Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1.Туган телне өйрәнүдә балалар фольклорының роле. Әкиятләр.<br>1.Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәре - әкиятләр күрсәтү. (хайваннар һәм көнкүреш әкиятләре);<br>2.Тәрбиячеләрнең докладлары белән танышу;<br>3. Әкиятләр буенча ясалган лэпбукларны презентацияләү; | ноябрь | Ливинова Э.Ф.<br>Морозова А.М.<br>Җамиева Г.Д.<br>Рахманова З.Н.<br><br>Төркем тәрбиячеләре.<br>Зиялиева Г.Р.<br>Галиуллина Д.М.<br>Гайнуллина А.Х.<br>Хуснутдинова Д.Н. |

## КҮРГӘЗМӘЛӘР, КОНКУРСЛАР

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | **«Көзге уңышлар»** композицияләр конкурсы | Август | пед.коллектив, профком |
| 2. | **«Әкиятләр илендә». (Татар халык әкиятләре).** | Ноябрь | пед. Коллектив<br>Тарат теле тәрбиячесе |
| 3. | **«Кыш бабай остаханәсе»** композицияләр күргәзмәсе | Декабрь | пед.коллектив |
| 4. | **Габдулла Тукай әсәрләре буенча күргәзмә** | Март<br>Апрель | Мөдир<br>Өлкән тәрбиясе |
| 5. | **«Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен»** | Апрель | Өлкән тәрбияче<br>Тарат теле тәрбиячесе |
| 6. | **Район, шәһәр, региональ, республика,Россия күләмендә үткәреләчәк конкурсларда катнашу** | ел дәвамында | Мөдир<br>Өлкән тәрбиче |

## 5.4. ТЕМАТИК КӨННӘР ҺӘМ АТНАЛЫКЛАР

### Тематик көннәр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Республика көне. | август | тәрбияче |
| 2. | “Белем” көне | сентябрь | тәрбияче |
| 3. | “Өлкәннәр көне” | октябрь | тәрбияче |
| 4. | “Педагоглар көне” | октябрь | тәрбияче |
| 5. | “Әниләр” көне | ноябрь | тәрбияче |
| 6. | “Китап көне” | февраль | тәрбияче |
| 7. | “Кошларны каршылау” | март | тәрбияче |
| 8. | “Бөтендөнья сәламәтлек көне” | апрель | тәрбияче |
| 9. | “Җинү көне” | май | тәрбияче |
| 10. | “Балаларны яклау” көне | июнь | тәрбияче |
| 11. | “Гаилә көне” | июль | тәрбияче |

## 5.5 КҮҢЕЛ АЧУ КИЧӘЛӘРЕ

| № | Исемлеге | Вакыты | Төркем |
|---|---|---|---|
| 1 | Күңел ачу “Хуш киләсең, ямьле көз” | Октябрь | 2 Кечкенәләр төркеме |
| 2 | Күңел ачу “Алтын көзгә сәяхәт” | Октябрь | Уртанчылар төркеме |
| 3 | Күңел ачу “Сөмбелә бәйрәме” | Октябрь | Зурлар төркеме |
| 4 | Күңел ачу “Сөмбелә бәйрәме” | Октябрь | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 5 | Ял кичәсе “Исәнме, чыршы” | Декабрь | 1 нче кечкенәләр төркеме |
| 6 | Ял кичәсе “Чыршы бәйрәме” | Декабрь | 2 нче кечкенәләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | төркеме |
| 7 | Ял кичәсе “Яңа ел тамашасы” | Декабрь | Уртанчылар төркеме |
| 8 | Ял кичәсе “Яңа ел могҗизасы” | Декабрь | Зурлар төркеме Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 9 | Күңел ачу “Хуш, чыршыкай!” | Январь | 1 кечкенәләр төркеме 2 нче кечкенәләр төркеме Уртанчылар төркеме Зурлар төркеме Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 10 | Күңел ачу “Безнең әтиләр” | Февраль | Зурларлар төркеме |
| 11 | Күңел ачу “Яле, егетләр” | Февраль | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 12 | Ял кичәсе “Әниләр бәйрәме” | Март | 2 нче кечкенәләр төркеме Уртанчылар төркеме |
| 13 | Ял кичәсе “8 Март – халыкара хатын кызлар бәйрәме” | Март | Зурлар төркеме Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 14 | Ял кичәсе “Нәүрүз бәйрәме” | Март | Зулар төркеме Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 15 | Әдәби-музыкаль кичә “Безнең Тукай бабабыз” | Апрель | Уртанчылар төркеме Зурлар төркеме |
| 16 | Ял кичәсе “9 Май – Җиңү көне” | Май | Зурлар төркеме Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 17 | Чыгарылыш кичәсе “Сау бул, бакча!” | Май | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| 18 | Күңел ачу “Күңелле Сабантуйлары” | Июнь | 2 нче кечкенәләр төркеме Уртанчылар төркеме Зурлар төркеме |

## 5.6 ТЕЛЛӘР ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Һәрбер балага ана телендә төрле яклап үсеш алу өчен шартлар тудыру, аралашу өчен телне сайлап алу иреге белән тәэмин итү. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 2 | Барлык төркемнәрдә дә тәрбия һәм белем бирү эшен туган телдә (татар телендә) оештыру. | Ел дәвамында | Бакча мөдире<br>Төркем тәрбиячеләр е |
| 3 | Дәүләт телләре турындагы законны үтәү максатыннан, балаларга татар һәм рус телләрен өйрәтүне оештыру. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 4 | Тематик шөгыльләр үткәрү – “Халкым мирасы”, “Ак калфак”“Җырлыйм дуслык турында” | кварталга бер | Тәрбиячеләр |
| 5 | Татар халык бәйрәмнәрен, күңел ачу иртәләре, атналыклар үткәрү - “Сабантуй”, “Нәүрүз”, “ Карга боткасы,“Әнигә”, “Әтиләр бәйрәме ”. | Ел дәвамында | музыка җитәкчеләре, тәрбиячеләр, татар теленә өйрәтүче тәрбиячеләр, төркем тәрбиячеләре |
| 6 | Габдулла Тукайның туган көненә багышлап шигырь бәйрәме үткәрү, конкурсларда катнашу | Апрель | Тәрбиячеләр |

## ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ УМКныКУЛЛАНУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ

***Максат:***
Ике телле шәхес тәрбияләүдә заманча алымнар кулланып халык авыз иҗаты аша балаларның сөйләм телен үстерү.

***Бурычлар:***
1.УМК материалларын төрле яшь үзенчәлекләре буенча аерым тәртипкә салырга, төркемнәргә кирәкле күрсәтмәлелек һәм видео –язмалар белән баетырга.
2. Эшчәнлекләрдә заманча алымнар кулланып, мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының татарча сөйләмен ныгытырга.
3.Заманча технологияләр кулланып балаларның сөйләм культурасын халык авыз иҗаты аша үстерүне дәвам итү.

**Сентябрь**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Балалар белән эш**<br>Төркемнәрдә аралашу мөһитләре булдыру.. | 1-2атна. |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | **Методик эш**<br>Кабинетта куллану өчен материаллар, уеннар ясауны дәвам итү. | ай дәвамында. |
| 3. | **Балалар белән эш**<br>Абдулла Алиш иҗаты белән танышуны дәвам итү. | 2атна |
| 4. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>“Туган жирем – Татарстан” , “Ата-аналар өчен”, ”Татарча өйрәнәбез “почмагын тулыландыруда ярдәм итү. | ай дәвамында |

**Октябрь**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Балалар белән эш**<br>Төркемнәрдә балаларның белем дәрәҗәләрен тикшерү. | 1-2атна. |
| 2. | **Методик эш**<br>Кабинетта укыту-тәрбия эше өчен яна методик әсбаплар туплауны дәвам итү | ай дәвамында |
| 3. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>“Көз бәйрәме”нә әзерлек эше<br>(уеннар, шигырь, җырлар өйрәнү). | 2-3атна |
| 4. | **Методик эш**<br>Яңа укыту методик комплекты программасы буенча эшчәнлекне системалаштыру, белем бирү эшчәнлеген берләштерү | ай дәвамында |

**Ноябрь**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>„Уйный-уйный үсәбез ”(зурлар төркеме) | 2атна |
| 2. | **Методик эш**<br>Хәрәкәтле, сүзле уеннар ясауны дәвам итү. | ай дәвамында. |
| 3. | **Ата-аналар белән эш.**<br>“Балаларны икетеллелеккә өйрәтү буенча УМК материаллары белән таныштыру эшен дәвам итү”. | 3атна. |
| 4. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>Тәрбиячеләр өчен  чыгыш. | 4атна |

**Декабрь**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Ата-аналар белән эш**<br>Әти-әниләр өчен чыгыш | 1 атна |
| | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>Идел буе халыкларынын гореф-гадәтләрен, милли уеннарын өйрәнүне дәвам итү. | ай дәвамында. |
| 2. | **Балалар белән эш**<br>Яңа ел бәйрәменә әзерләнү:<br>уеннар, шигырь, җырлар өйрәнү. | 3 атна |
| 3. | **Ата-аналар белән эш:**<br>анкета уздыру | 4 атна |

**Январь**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1.. | **Балалар белән эш**<br>Чыршы белән саубуллашу. | 3 атна |
| 2.. | **Ата- аналар белән эш**<br>Чыгыш-презентация | 4 атна |
| 3. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>УМК буенча дидактик уеннар әзерләүне дәвам итү. | ай дәвамында |
| 4. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>Ата – аналар почмаклары өчен “Мы изучаем татарский язык”, “Татар телен өйрәнәбез” папкаларындагы материалларны яңату. | ай дәвамында |

**Февраль**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Мәктәп белән эш**<br>Балалар бакчасында һәм мәктәптә караган мероприятиеләргә анализ. | ай дәвамында |
| 2. | **Тәрбиячеләр белән эш**<br>Туган телгә багышланган шигырь бәйгесе<br>“Туган телем иркә гөлем”(зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре) | 3 атна |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | **Балалар белән эш**<br>21 февраль халык-ара туган телләр көне.<br>төркемнәрдә бәйрәм кичәсе) | 3 атна |
| 4. | **Балалар белән эш**<br>«Тылсымлы әкиятләр»(мәктәпкә хәзерлек төркеме) | ай дәвамында |
| 5. | **Балалар белән эш**<br>“Мультфильмнар илендә ” – рәсем кургәзмәсе | 4 атна |

**Март**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Балалар белән эш**<br>8 март иртәләре:<br>Әнием-кадерлем, минем иң якыным” (төркемнәрдә күңел ачу иртәсенә әзерлек эше, уеннар, шигырь, җырлар өйрәнү). | 2 атна |
| 2. | **Балалар белән эш**<br>Татар халкының милли бәйрәме “Нәүрүз” (Күңел ачу кичәсе) | 3 атна. |
| 3. | **Мәктәп белән эш**<br>Чыгарылыш төркем балаларының өлгерешләре белән танышу. | 3 атна |
| 4. | **Балалар белән эш**<br>Телне авыр үзләштерүче балалар белән аерым шөгыльләнү. | ай дәвамында |

**Апрель**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Балалар белән эш**<br>1.Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган кичә. УМК(Тукай әкиятләре буенча)<br>2.Габдулла Тукай әсәрләре буенча (кулдан эшләнгән материаллар белән ясалган эшләр) күргәзмә.<br>3. „Серле Тукай дөньясы” УМК(мультфильмнар карау)<br>4. Безнең уңышлар һәм киләчәккә планнар | ай дәвамында |
| 2. | Габдулла Тукай әсәрләре буенча (кулдан эшләнгән материаллар белән ясалган эшләр) күргәзмә. | 3 атна |
| 3. | **Балалар белән эш**<br>Шигырь бәйгесе «Без-Тукай оныклары». (уртанчылар төркеме балалары) | 4атна |

**Май**

| № | Эчтәлек | үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | **Балалар белән эш**<br>Чыгарылыш иртәләре „Саубул, матур бакчабыз!” (оештыруда ярдәм итү) | ай дәвамында. |
| 2. | **Тэрбиячеләр белән эш**<br>Чыгарылыш иртәсе: „Саубул, матур бакчабыз!” | 4 атна |
| 3. | **Ата-аналар белән эш**<br>“Ирешелгән уңышлар, киләчәккә паннар” (УМК)-нәтиҗәләр белән таныштыру | ай дәвамында. |
| 4. | **Тэрбиячеләр белән эш**<br>“Сабантуй” бәйрәменә әзерлек | 4атна |

## 5.7 ТӘРБИЯҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНӘ ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ
## ҺӘМ КОНТРОЛЬ.

### Оператив тикшерүләр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемнең яңа уку елына әзерлеген тикшерү. | ноябрь | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 2. | Йомгаклау эшчәнлеген карау | Квартал саен | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 3. | Тәрбияченең, перспектив планнарын, документацияләрен, ата-аналар почмагын һ.б.тикшерү. | ноябрь | Бакча мөдире, өлкән тәрияче |
| 4. | төркемдә дә тәрбия һәм белем бирү эшенә контроль ясау. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 5. | Тәрбияченең, белгечләрнең календарь планнарын вакытында төзүләрен тикшереп тору. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 6. | Иртәнге гимнастиканың системалы һәм программа таләпләренә туры китереп үткәрелүен контрольдә тоту. | Ел дәвамында, системалы рәвештә | Бакча мөдире, өлкән тәрияче |
| 7. | Балалар иртәләрен, музыкаль күңел ачуларны, физкультура мавыктыргыч уеннарны оештыруны һәм үткәрүне контрольгә алу. | Ел дәвамында | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |
| 8. | Төркемнәрдә әти-әниләр җыелышын оештыруга һәм үткәрүгә контроль | Квартал саен | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |

### Тематик тикшерүләр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның туган телне үзләштерү буенча сөйләм күрсәткечләре (зурлар төркеме) | январь | Өлкән тәрбияче |
| 2. | Мәктәпкәчә яштәге балаларда финанс грамоталылыгын формалаштыру эшен оештыру | март | Өлкән тәрбияче |

## 6. ӘТИ-ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ
### 6.1 Гомуми әти-әниләр җыелышы

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| I | Балалар бакчасының 2023-2024 уку елына алынган бурычлары белән таныштыру. | Сентябрь | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Әти-әниләр комитеты рәисенең узган уку елында эшләнгән эшенә отчетын тыңлау | | |
| 3 | Әти-әниләр комитетын сайлау | | |
| 4 | Төрлесе | | |
| **II** | **Тема: “Безнең уңышлар”** | Май | Бакча мөдире |
| 1 | Баланың шәхесен һәрьяклап үстерү чарасы буларак уртак тәрбия-белем бирү процессына йомгак ясау. | | Тәрбияче, ата-аналар |
| 2 | “Баланың сәламәтлеген бергә нygытыйк, саклыйк” | | шәфкать туташы |
| 3. | Актив әти-әниләргә рәхмәт белдерү. | | Мөдир |

**6.2 “Авыр гаиләләр” белән эш планы**

| **№ п/п** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1 | Балаларны тәрбияләүгә салкын караучы гаиләләрне ачыклау һәм күзәтү | Ел дәвамында | Төркем тәрбиячеләре, өлкән тәрбияче |
| 2 | Режим, туклану һәм балаларны тәрбияләү буенча консуль-тацияләр, әңгәмәләр оештыру | Ел дәвамында | Бакча мөдире, тәрбияче |

**6.3 Әти-әниләр өчен консультацияләр**

| **№ п/п** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1 | “Балалар бакчасында адаптация чоры” | Сентябрь | Тәрбияче |
| 2 | “Сак булыгыз: грипп” | Октябрь | Шәфкать туташы Тәрбияче |
| 3 | “Нәниләрнең сөйләм телен үстерүдә уен алымын куллану” | Ноябрь | Тәрбияче |
| 4 | “Сез юл йөрү кагыйдәләрен беләсезме?” | Февраль | Тәрбияче |
| 5 | “Балагыз мәктәпкә әзерме?” | Апрель | Тәрбияче |

**6.4 “Ачык ишекләр” көне.**

| **№** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1 | «Балалар бакчасында балалар белән эшләү формалары». | Февраль | Бакча мөдире, тәрбияче |

**6.5 Әти-әниләр комитеты белән эш**

| **№** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1 | Әти-әниләр комитетын оештыру | Сентябрь | Бакча мөдире, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | төркем тәрбиячеләре |
| 2 | Көзге бәйрәм иртәләрендә катнашуларын оештыру | Октябрь | Өлкән тәрбияче, музыка җитәкчесе, төркем тәрбиячеләре |
| 3 | Ачык ишекләр көне оештыру | Ноябрь | Бакча мөдире, өлкән тәрбияче, белгечләр, төркем тәрбиячеләре |
| 4 | Яңа ел бәйрәм иртәләрен оештыруда ярдәм күрсәтү | Декабрь | Музыка җитәкчесе, төркем тәрбиячеләре |
| 5 | Әниләр бәйрәменә багышланган бәйрәм иртәләрендә катнашуны оештыру | Март | Музыка җитәкчесе, төркем тәрбиячеләре |

## 7. МӘКТӘП БЕЛӘН ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШ

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | 1 Сентябрь көнне уку елы башлануга багышланган тантаналы линейкада катнашу | сентябрь | Тәрбияче,ата-аналар |
| 2. | Мәктәпнең сыйныф бүлмәләре, китапха-нә, спорт залы, музей бүлмәләренә экскурсияләр оештыру | сентябрь | тәрбияче |
| 3. | Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендәге балаларга «Мәктәп һәм мәктәп әсбаплары» дигән темага әңгәмә оештыру | I квартал | тәрбияче |
| 4. | Мәктәп укучыларын балалар бакчасында үткәрелгән атналыкларда катнашуларын оештыру. Башлангыч класс укучыларын. «Белем», «Милли мәдәният», «Гүзәллек» атналыгы. | ел дәвамында | тәрбияче |

### Методик эш

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Башлангыч сыйныфларда уку-укыту буенча директор урынбасары белән мәктәп һәм балалар бакчасы арасында бергәләшеп эшләү планын төзү һәм раслау | сентябрь | Бакча мөдире , директор урынбасары |
| 2. | Мәктәптә укучы –балалар бакчасына йөргән балаларның өлгереше турында тәрбиячеләр отчеты | ноябрь | тәрбияче |
| 3. | Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучыларының һәм тәрбиячеләрнең үзара дәресләр һәм шөгыльләр каравын оештыру | | Бакча мөдире , башлангыч сыйныфлар буенча директор урынбас. |
| 4. | Мәктәпнең психологын һәм укытучыларын ата – аналар белән очрашу кичәләренә чакыру | апрель | Бакча мөдире |

## 8. АДМИНИСТРАТИВ-ХУЖАЛЫК ЭШЛӘРЕ

| № п/п | Эшләнәсе эшләр | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Финанс – экономия эшенә анализ ясау. Отчетланы төгәл, вакытында бирү | Ай саен | Бакча мөдире |
| 2. | Инвентаризация эшләрен төгәл, вакытында башкару | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 3. | Роспотребнадзор, МЧС предписанияләрен вакытында үтәү | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 4. | Балалар мебелендәге маркировканы яңарту | август | Кече тәрбияче |
| 5. | Яшелчә складын яшелчә кабул итүгә әзерләү (акшарлау, дизенфекцияләү) | август | Кече тәрбияче,тәрбияче |
| 6. | Әвәләү шөгыльләре өчен балчык әзерләү | август | тәрбияче |
| 7. | Балалар бакчасы бинасын кышка әзерләү (ишек, тәрәзәләрне ныгыту, җылыту) | октябрь | Кече тәрбияче |
| 8. | Клумбаларга күпъеллык чәчәкләр утыртуны дәвам итү | сентябрь | Кече тәрбияче |
| 9. | Ишек алдын себеру очен хэм кар көрәү өчен эш кораллары белән тәэмин итү | август | Бакча мөдире. |
| 10 | Яктырту, җылылык системасын һәм судан дөрес, экономияле файдалану | ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 11 | Балалар бакчасы территориясендә оештыру эшләре: куакларны тигезләп кисү, агачларның корыган ботакларын кисү, яңа куаклар утырту, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасын казу, чүп үләннәреннән чистарту, яшелчә бакчасын тәртиптә тоту өчен даими рәвештә санитар чәршәмбеләр оештыру | сентябрь | коллектив |
| 12 | Техник куркынычсызлык кагыйдәләрен, янгын, СанПиН таләпләрен төгәл үтәү | ел дәвамында | Бакча мөдире |

**9.Сәламәтләндерү һәм авыруларны кисәтү буенча еллык эш планы**

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның физик үсешен тикшерү | елга 2-4 тапкыр | Тәрбияче |
| 2. | Балаларның сәламәтлек торышын күзәтү:<br>1) иртәнге фильтр вакытында;<br>2) реконвалесцент балаларны кабул иткәндә;<br>3) яңа килгән балаларны кабул иткәндә; | даими | Тәрбияче |
| 3. | Физкультура шөгыле буенча балаларны сәламәтлек төркеменә бүлү. | елга бер тапкыр | Тәрбияче |
| 5. | Сәламәтләндерү чаралары:<br>1. Витаминотерапия.<br>2. Фитонцидлар куллану, оксолин мазе куллану<br><br>4. Температура үзгәрүенә карап балаларны саф һавада кабул итү<br>5. Саф һавада гимнастика үткәрү | План буенча<br>Инфекция чорында<br>Даими | Өлкән шәфкать туташы, төркем тэрбиячеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Даими | |
| 6. | Физик тәрбия һәм чыныктыру чаралары:<br>1. Коры уыну<br>2. Тозлы, сәламәтләндерү җәймәләрендә йөрү<br>5. Сулыш гимнастикасы<br>6. Музыкаль- ритмик хәрәкәтләр<br>7. Авазлар белән сәламәтләндерү | Даими | Төркем тәрбиячеләре |
| 7. | Туклану:<br>1. Меню төзү,<br>2. Әзер продукциягә бракераж үткәрү,<br>3. Тиз бозылучан продукциягә бракераж үткәрү<br>4. Натураль нормаларның үтәлешен контрольдә тоту<br>5. Кухняда санитария-гигена таләпләрен үтәүне күзәтү<br>6. Калория санау. | Көндәлек<br>Көндәлек<br>Продукция килгәч<br>Даими<br>Көндәлек<br>10 көн саен | Мөдир,<br>Өлкән шәфкать туташы. |
| 8. | Сәламәт яшәү, гигиеник тәрбия бирү буенча санитари-агарту эшләре алып бару. | Даими | Өлкән шәфкать туташы.,өлкән тәрбияче |
| 9. | Гәүдә торышында, күзләрдә, ишетү органнарында килеп чыккан авыруларны контрольдә тоту | Даими | Өлкән шәфкать туташы |
| 10. | Гигиеник тәрбия процессларын, режим моментларын, балаларның хәрәкәт режимын күзәтү | Көндәлек | Өлкән шәфкать туташы,<br>мөдир |
| 11. | Балаларны медицина тикшерүенә әзерләү | График нигезендә | Өлкән шәфкать туташы, мөдир |
| 12. | Балаларны гельминт чирләренә тикшерүне оештыру | График нигезендә | Өлкән шәфкать туташы,<br>мөдир |
| 13. | Инфекцион авырулар белән контактта булганнарны күзәтү | Инфекция очрагында | Өлкән шәфкать туташы,мөдир |
| 14. | Төркемдә санитария-дезинфекция режимнары үтәлешен тикшерү, җилләтү режимнарын контрольдә тоту. | Даими | мөдир |
| 15. | СанПин таләпләрен үтәү буенча хезмәткәрләр белән инструктаж | Айга бер тапкыр | мөдир |
| 16. | Генераль җыештыруны оештыру | Айга бер тапкыр | мөдир |
| 18. | Балалар бакчасында территория чисталыгын, яшелләндерүне контрольдә тоту | Даими | мөдир |
| 19. | Травматизмны кисәтү максатыннан спорт инвентарьларының төзеклеген тикшерү | Атнага ике тапкыр | мөдир |
| 20. | Балаларның буена үлчәп, мебельләрне комплектлаштыру | Елга бер тапкыр | Тәрбияче |
| 21. | Хезмәткәрләрне йогышлы һәм тире авыруларына тикшерү. | Көндәлек | тэрбияче |
| 22. | Дез. препаратларының сакланышын, күзәтеп бару | Көнгә ике тапкыр | мөдир |
| 23. | Әти-әниләр җыелышларында чыгышлар | План буенча | Өлкән шәфкать туташы, |

**10. Юл кагыйдәләрен өйрәтү буенча эш планы**

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Перспектив планнар, программаларны һәм методик әсбапларны раслау | Август | Мөдир |
| 2 | Төркем бүлмәсендә һәм ата – аналар өчен “Юл йөрү кагыйдәләре” почмагын җиһазлау | Август | Тәрбияче |
| 3 | Юл кагыйдәләрен өйрәтү шөгыльләре | Елдәвамында тәрбиячнең календарь планнары буенча | Тәрбияче |
| 4 | Юл кагыйдәләрен өйрәтү буенча дидактик уеннар ясау, күргәзмә әсбаплар сатып алу | Ел дәвамында | Ата-аналар, Тәрбияче |
| 5 | Стенд материалларын яңартып тору | Даими | Тәрбияче |
| 6 | Кабатлау-комплексллы шөгыльләр | Квартал саен | Тәрбияче |
| 7 | Экскурсияләр: | тәрбияченең календарь планы буенча | Тәрбияче |
| 8 | Видеофильмнар, слайдлар карау | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 9 | Прогулкаларда юл йөрү кагыйдәләрен искәртүче хәрәкәтле уеннар уйнау | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 10 | Рәсем ясау, әвәләү һәм кисеп ябыштыру. (Транспорт төрләре, урамнары) | шөгыльләрдән тыш һәм буш вакытларда | Тәрбияче |